**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

**«6» октября 2025ел** **№ 138**

2026 елга Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасының сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары нигезендә, ДБУ «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге»нең 2025 елның 26 сентябрендәге 01/1608 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елга расларга:

1.1. Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар, кушымта нигезендә;

1.2. сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга 0,85 күләмендә төзәтмә коэффициенты.

2. Муниципаль район Башкарма комитетының Финанс-бюджет палатасына (Р.Р. Яхин) әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«6» 10 2025 № 138
номерлы карарына кушымта

2026 елга Теләче муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар (бер укучыга бер елга сумнарда) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өчьеллык укыту срогы | дүртьеллык укыту срогы | бишьеллык укыту срогы | җидееллык укыту срогы | сигезьеллык укыту срогы | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | авыл җирлеге | 104 247 | 99 756 | 101 088 | 116 348 | 118 295 | 157 454 |
| Сынлы сәнгать | авыл җирлеге | | 52 078 | 44 324 | 41 001 | 45 254 | 103 657 |
| Хореография сәнгате | авыл җирлеге | | | 101 666 | 82 983 | 85 697 | 358 407 |
| Гомуми эстетик сәнгать | авыл җирлеге | | | 45 469 | | | |
| Фольклор сәнгате | авыл җирлеге | | | 105 731 | 101 809 | 102 618 | 173 253 |
| Эстрада-джаз сәнгате | авыл җирлеге | 171 693 | | 157 939 | | | 275 771 |
| Театр сәнгате | авыл җирлеге | 81 056 | 73 192 | 75 802 | 75 771 | 77 485 | 112 534 |